ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03.11.2020 № 898

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 12 ноябрендәге 925 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен, эшләр, хезмәт күрсәтүләр, товарлар сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында 2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 12 ноябрендәге 925 номерлы карары белән Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының контракт хезмәте турындагы яңа редакциядә расланган нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

10 пунктның 17 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17) тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү нәтиҗәләренә карата шикаять белдерү турындагы эшләрне карауда катнашалар һәм дәгъвалау-дәгъва эше башкару өчен материаллар әзерлиләр.».

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Хәмзин